РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнтельный комитет
Нижнеуратьминского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Уратма авыл жирлеге
Башкарма комитеты

423567, Нижнекамский район,
с. Нижняя Уратьма ул. Центральная, 1

423567, Түбән Кама районы,
Түбән Уратма авылы, Үзәк урамы, 1

тел./факс (8555) 33-17-25, электронный адрес: Nizhneuratminskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.nizhneuratminskoe-sp.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 31.01.2019 ел № 1

Түбән Уратма авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыручаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары белән, карар бирәм:

1. 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә таянып, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2019 елның 1 февраленнән Түбән Уратма авыл җирлегендә җирләү 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Түбән Уратма авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Р.Гарифуллин

Түбән Уратма авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31 гыйнварында
2 номерлы карарына
1нче кушымта

Түбән Уратма авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 5 000 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Түбән Уратма авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 31 гыйнварында
2 номерлы карарына
2нче кушымта

Түбән Уратма авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтүнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар рәсмиләштерү | 46,47 |
| 2. Гәүдәне киендерү | 245 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм илтү | 450 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) илтү | 450 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4755 |
| Барлыгы | 5946,47 |